КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 17 август г.Казань № 850

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия кредит оешмаларында җәлеп ителгән кредитлар буенча процентларны түләүгә бәйле чыгымнарны каплауга субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2020 ел, 28 сентябрь, 875 нче карары белән расланган Россия кредит оешмаларында җәлеп ителгән кредитлар буенча процентларны түләүгә бәйле чыгымнарны каплауга субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия кредит оешмаларында җәлеп ителгән кредитлар буенча процентларны түләүгә бәйле чыгымнарны каплауга субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2020 ел, 28 сентябрь, 875 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 31 май, 398 нче, 2022 ел, 28 март, 277 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Россия кредит оешмаларында җәлеп ителгән кредитлар буенча процентларны түләүгә бәйле чыгымнарны каплауга субсидияләр бирү тәртибенә (алга таба – Тәртип) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

5.1 пунктның өченче абзацында «субсидия алучының субсидия алучы тарафыннан субсидия алучының һәм аны бирү шартларының, максатларының һәм тәртибенең үтәлешенә дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан тикшерүләр үткәрүгә ризалыгы» сүзләрен төшереп калдырырга;

5.6 пунктта:

алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Вәкаләтле орган субсидия алучының субсидия бирү тәртибен һәм шартларын үтәвен, шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү өлешендә тикшерүне гамәлгә ашыра. Дәүләт финанс контроле органнары Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә тикшерү үткәрә.»;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешүне мониторинглау килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешүдән һәм субсидия бирү нәтиҗәсен алу буенча тиешле чараны төгәлләү факты чагылдырыла торган вакыйгалардан (контроль нокта) чыгып, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм формалар буенча гамәлгә ашырыла.»;

2. Тәртипнең 2.1 пунктындагы өченче абзацының һәм Тәртипнең 5 нче кушымтасындагы өченче абзацының гамәлдә булуын 2023 елның 1 гыйнварына кадәр туктатып торырга.

3. Бу карар (бу карарның 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә торган 1 пунктындагы җиденче абзацыннан тыш) рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин